**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 16 май | № 347

г. Казань

«2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» Татарстан Республикасы законы проекты һәм 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең озак вакытлы фаразы хакында

Татарстан Республикасы икътисад министры А.А.Здуновның «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» Татарстан Республикасы законы проекты һәм 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең озак вакытлы фаразы хакында докладын, 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенең төп юнәлешләре турында Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры Р.Х.Зариповның, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры М.Г.Әхмәтовның, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры И.Ә.Фәйзуллинның, Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Л.Р.Сафинның, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары А.И.Поминовның, Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе урынбасары М.З.Бохараевның чыгышларын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Алга таба Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү өчен «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» Татарстан Республикасы законы проектын хупларга.

2. Бу карарга теркәлгән 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең озак вакытлы фаразын расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры | И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\347.docx

Татарстан Республикасы
Министлар Кабинетының
2015 ел, 16 май, 347 нче
карары белән расланды

**2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең озак вакытлы фаразы**

***Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең төп тенденцияләре***

2014 елда Татарстан Республикасында, гомумән, Россиядә кебек үк, тышкы икътисадый шартлар катлаулануы һәм санкция чикләүләре кертү белән бәйле, икътисадый үсешнең тоткарланган динамикасы күзәтелә. 2014 елның нәтиҗәләре буенча, тулаем төбәк продуктының үсеш темпы, бәяләү буенча, узган ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 101,3 процент тәшкил итә (2009 елның дәрәҗәсенә карата 120,6 процент). Гомумән алганда, республика буенча тулаем төбәк продуктының күләме, бәяләү буенча, 1 631,4 млрд.сум тәшкил итә.

2014 елда сәнәгать җитештерүенең уңай динамикасы, узган елга карата үсеш темпларын шактый акрынайтып саклана. Сәнәгать җитештерүе индексы узган ел дәрәҗәсенә карата 100,6 процент тәшкил итә, төяп җибәрелгән продукциянең күләме 1 641,5 млрд.сумга җитә. Соңгы биш ел эчендә сәнәгать җитештерүе күләме 2009 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 1,2 тапкырга үсә.

Файдалы казылмалар чыгаруда 2014 елда җитештерү индексы 2013 ел дәрәҗәсенә карата 100,8 процент тәшкил итә (2009 ел дәрәҗәсенә карата 102,3 процент), эшкәртү производстволарында – 100,9 процент (2009 ел дәрәҗәсенә карата 1,5 тапкырга үсү), электр энергиясе, газ һәм суны җитештерүдә һәм бүлүдә – 96,8 процент (2009 ел дәрәҗәсенә карата 101,5 процент).

2014 елда республиканың икътисадына һәм социаль өлкәсенә җәлеп ителгән төп капиталга инвестицияләр 542,8 млрд.сум тәшкил итә (2013 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 100 процент). 2010 – 2014 елларда республикада икътисадны һәм социаль өлкәне үстерүгә җәлеп ителгән төп капиталга инвестицияләр 2,3 трлн.сумга якын тәшкил итә. Нәтиҗәдә тулаем төбәк продуктында төп капиталга инвестицияләр өлеше, бәяләү буенча, 33,3 процент тәшкил итә (2009 елда – 31,4 процент).

Инвестиция өлкәсендә динамиканың акрынаю, үз чиратында, төзелеш секторының үсеш темпларында чагыла. «Төзелеш» эшчәнлек төре буенча башкарылган эшләрнең күләме 2014 елда 266,5 млрд.сум яки 2013 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 100 процент тәшкил итә (2009 ел дәрәҗәсенә карата 1,4 тапкырга үсү).

Төзелгән торак күләме 2014 елда 2 404,2 мең кв.метр яки 2013 ел дәрәҗәсенә карата 100,2 процент тәшкил итә. 2010 – 2014 елларда республикада 11,6 млн.кв.метр торак кертелә.

2014 ел авыл хуҗалыгы өчен уңышлы була, барлык авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең авыл хуҗалыгы продукциясе күләме 188,8 млрд.сум яки

2013 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 102,3 процент тәшкил итә (2009 ел дәрәҗәсенә карата 95,2 процент).

2014 елның икенче яртысында эчке базарда сорауның кимүе күзәтелә. Нәтиҗәдә ваклап сату әйләнешенең үсеш темплары узган ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә – 102,3 процент, ваклап сату әйләнеше 781 млрд.сум тәшкил итә. Соңгы 5 ел эчендә ваклап сату әйләнеше 2009 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 1,5 тапкырга арта.

Кулланучылар бәяләренең ел башыннан үсүе (2013 елның декабренә карата 2014 елның декабре) 109,7 процент тәшкил итә. Шул ук вакытта азык-төлек товарларына бәяләр үсүе – 114,2 процент, азык-төлеккә карамаган товарларга – 105,9 процент, халыкка түләүле хезмәтләр күрсәтү 108,9 процент тәшкил итә.

Социаль өлкәдә, икътисадтагы үсеш темплары акрынаюга карамастан, 2014 елда төп күрсәткечләр буенча уңай динамика саклана. Республиканың предприятиеләрендә һәм оешмаларында, кече эшмәкәрлекне кертеп, эшләүчеләргә күчерелгән уртача эш хакы 28 352,2 сум тәшкил итә һәм 2013 ел белән чагыштырганда 9,5 процентка арта (2009 ел дәрәҗәсенә карата 1,9 тапкырга үсү). Товарлар һәм хезмәтләргә кулланучылар бәяләре индексын исәпкә алып хисапланган гамәлдәге эш хакының үсеш темпы 102 процент тәшкил итә (2009 ел дәрәҗәсенә карата 1,4 тапкырга үсү).

Республиканың хезмәт базарындагы хәле 2014 ел дәвамында чагыштырмача тотрыклы кала. Теркәлгән эшсез гражданнар саны, 2013 ел ахырындагы мәгълүматлар белән чагыштырганда, 2,2 тыс.кешегә кими һәм 2014 елның декабре ахырына 15,2 мең кеше тәшкил итә. Эшсезлек дәрәҗәсе соңгы 5 ел эчендә минималь булып тора (республиканың икътисадый актив халкыннан 0,74 процент). Шунысын әйтергә кирәк: эшсезлек дәрәҗәсенең кимүе яңа эш урыннары булдыру белән генә түгел, хезмәткә сәләтле яшьтәге халык санының кимүе белән дә бәйле (соңгы 5 ел эчендә 80 мең кешедән артык).

2011 елда демографик хәлдә Татарстан Республикасында узган 19 елга беренче тапкыр халыкның табигый артымы теркәлә (табигый артым коэффициенты 1000 кешегә (+) 1,0) 2009 елдагы табигый кимүгә каршы (табигый кимү коэффициенты 1000 кешегә (–) 0,4). 2014 елда туучылар санының үлүчеләр саныннан артыграк булу унай тенденциясе саклана. Халыкның табигый артымы 9,6 мең кеше тәшкил итә, табигый артым коэффициенты 1000 кешегә 2,5.

2015 елда республикада икътисадый активлык кимү тенденциясе күзәтелә. Агымдагы елның гыйнвар – мартында тулаем төбәк продуктының күләме, бәяләү буенча, периода 2014 елның тиешле чоры дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 0,4 процентка кими һәм 349,1 млрд.сум тәшкил итә. Гомумән алганда, бер ел эчендә тулаем төбәк продукты, фаразлау нигезендә, 2014 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 1 процентка кимиячәк.

Сәнәгать җитештерүе темпларының кимүе күзәтелә. Агымдагы елның гыйнвар – мартында сәнәгать җитештерүе индексы 2014 елның тиешле чоры дәрәҗәсенә карата 99,5 процент тәшкил итә. Эшкәртү производстволарында җитештерү индексы 2014 елның гыйнвар – марты дәрәҗәсенә карата – 1,5 процентка, электр энергиясе, газ һәм суны җитештерүдә һәм бүлүдә 3,9 процентка кими.

Шул ук вакытта файдалы казылмалар чыгаруда житештерү индексы 1,3 процентка арта.

Ел нәтиҗәләре буенча сәнәгать җитештерүе индексы 2014 ел дәрәҗәсенә карата 99,7 процент дәрәҗәсендә фаразлана, һәм ул житештерү производстволарында (99,7 процент), шулай ук электр энергиясе, газ һәм суны җитештерүдә һәм бүлүдә (97 процент) динамиканың кыскаруы белән бәйле. Уңай динамика саклануы файдалы казылмалар чыгаруда фаразлана (100,7 процент).

2015 елның гыйнвар – мартында төзелеш күләмнәре шактый кими. «Төзелеш» эшчәнлек төре буенча башкарылган эшләрнең күләме 33,6 млрд.сум яки 2014 елның тиешле чоры дәрәҗәсенә карата 87,9 процент тәшкил итә. Торак кертү 2014 елның гыйнвар – марты дәрәҗәсенә карата 20,2 процентка кими һәм 573,8 мең кв.метр тәшкил итә. Ел нәтиҗәләре буенча, «Төзелеш» эшчәнлек төре буенча башкарылган эшләрнең күләме 2014 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 98 процент дәрәҗәсендә фаразлана.

2015 елның гыйнвар – мартында авыл хуҗалыгы продукциясенең күләме 36,1 млрд.сум тәшкил итә һәм чагыштырма бәядә 2014 елның тиешле чоры дәрәҗәсеннән 1,5 процентка арта. Агымдагы елда авыл хуҗалыгы, фараз буенча, уңай динамиканы саклаячак – 2014 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 102,6 процент.

Гамәлдәге акчалата керемнәрнең кимүе һәм инфляциянең югары темплары җирлегендә кулланучылар базарында халыкның сатып алу соравы кимүе күзәтелә. 2015 елның гыйнвар – мартында ваклап сату әйләнеше 170,4 млрд.сум тәшкил итә, һәм ул чагыштырма бәяләрдә 2014 елның гыйнвар – марты дәрәҗәсеннән 15,3 процентка кимрәк. 2015 елда республикада ваклап сату товарлары әйләнеше, фараз буенча, 2014 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 10 процентка кимиячәк.

Кулланучылар бәяләре индексы 2014 елның декабренә мөнәсәбәттә агымдагы елның мартында 105,9 процент тәшкил итә, шул исәптән азык-төлек товарларына – 109,2 процент, азык-төлеккә карамаган товарларга – 105,4 процент, хезмәтләр күрсәтүгә – 102,4 процент. Ел нәтиҗәләре буенча инфляция 2014 елның декабренә карата 111,2 процент дәрәҗәсендә фаразлана.

Республиканың предприятиеләрендә һәм оешмаларында, кече эшмәкәрлекне кертеп, эшләүчеләргә күчерелгән уртача эш хакы 2014 елның гыйнвар-феврале дәрәҗәсенә карата 8,9 процентка арта һәм 26 943,4 сум тәшкил итә. Гамәлдәге эш хакы 3,3 процентка кими. 2015 елда уртача айлык эш хакы, фараз буенча, составит 30 192 сум тәшкил итәчәк, гамәли чагылышта – 94,1 процент.

2015 елның марты ахырына халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләрендә 17,5 мең эшсез граждан яки республиканың икътисадый актив халкының 0,85 проценты исәптә тора (2014 елның марты ахырына – 0,89 процент). Ел нәтиҗәләре буенча теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе икътисадый актив халыкның 1 проценты дәрәҗәсендә фаразлана.

Агымдагы елның гыйнвар – мартында халыкның табигый артымы 1 286 кеше тәшкил итә. Табигый артым коэффициенты 1000 кешегә 1,4 тәшкил итә, һәм ул туучылар санының үлүчеләр саныннан артыграк булуы белән бәйле.

***Озак вакытлы чорга үстерүнең төп проблемалары һәм куркынычлары***

Фаразлау чоры, бер яктан, беренче этапта дөнья икътисадының үсеш перспективаларына мөнәсәбәттә югары геосәяси куркынычлар һәм билгесезлек саклануы белән характерлана, икенче яктан – кластер инициативалары кысаларында стратегия максатларын гамәлгә ашыруга, инвестицион климатны яхшыртуга, конкурентлыкка сәләтне һәм бизнес нәтиҗәлелеген күтәрүгә, икътисадый үсешне стимуллаштыруга һәм модернизацияләүгә нигезләнә.

Мөмкин булган куркынычлар:

төбәк икътисадында һәм, гомумән, Россия Федерациясендә хәлнең начараюы: инвестицион климатның начараюы, инфляция үсеше, сум курсының көчсезләнүе, продукциянең үзкыйммәте үсү, капиталны үзләштерү шартлары начараю һәм капитал агымнары көчәю, табигый монополия тарифлары үсү, ягулыкның һәм электр энергиясенең төп төрләренә бәяләр күтәрелү, төп чимал һәм материалларга бәяләр күтәрелү, транспорт һәм иминият компанияләре тарафыннан йөкләрне ташу һәм иминиятләүгә бәяләрне күтәрү;

продукция экспортына һәм технологияләр сатып алуга тискәре йогынты күрсәтәчәк геосәяси хәлнең катлаулануы, санкцияләр сәясәтен һәм чикләүләрне дәвам итү;

конкурентлар арасындагы көрәшнең катгыйлануы, билгесезлек, коммерция һәм финанс куркынычларының үсүе;

бизнес алып баруны җайга салучы шартларның начараю;

квалификацияле кадр җитмәве, начар демографик хәл, кеше капиталын үстерү системасы проблемалары, хезмәт базарында ихтыяҗ зур булган урта буын белгечләр булмавы.

***2030 елга кадәр чорга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең озак вакытлы фаразы вариантларын тасвирлау***

Тышкы шартлар фаразының билгесезлеге 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының сценарий вариантларын куллану кирәклегенә шарт була:

1 сценарий – инерцион (катгый ресурслар чикләүләре сценарие);

2 сценарий – база (уртача ресурслар чикләүләре сценарие);

3 сценарий – оптимистик (җиңелчә ресурслар чикләүләре сценарие).

2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының һәр өч вариант буенча төп күрсәткечләре әлеге Озак вакытлы фаразга теркәлгән 1 – 3 нче кушымталарда күрсәтелә.

**Инерцион сценарий (1 вариант)**. Икътисадый үсеш темпларын тизләтүне күздә тотмый (тышкы факторларның йогынтысына бәйле хәлнең вакытлыча начараюы ихтимал), үстерү «стандарт» инерцион трендлар буенча бара, ресурслар чикләүләре үтеп булмый. Ресурслар чикләүләрен исәпкә алып, бары иң өстенлекле һәм иң аз ресурслар сыйдырышлы проектлар гына гамәлгә ашырыла (проектларны гамәлгә ашыру вакытларын соңрак вакытка күчерү ихтимал).

Сценарийның төп параметрлары:

республиканың күпчелек икътисад тармакларының конкурентлыкка сәләттә иң яхшы чит ил җитештерүчеләре дәрәҗәсеннән артта калуны бераз киметүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирүче тотрыклы үсеш моделе формалаштыру максаты белән, традицион өлкәләрдәге конкурентлык өстенлекләрен ныгыту һәм киңәйтү, һәм бу республиканың икътисадый структурасын бераз модернизацияләүгә китерәчәк;

кеше капиталының бераз үсүе;

икътисадый һәм социаль өлкәләрнең чагыштырма өстнелекләрен гамәлгә ашыручы озак вакытлы өстенлекле проектлар һәм программаларның чикләнгән күләмен гамәлгә ашыру;

инвестицияләрне җәлеп итүне бераз үстерү;

пространство үсеше шартларын формалаштыру;

төбәкара һәм халыкара социаль-икътисадый пространствода интеграцион процессларны киңәйтү;

балансլаштырылган тотрыклы үсешкә китерүче институциональ мохитне үстерү;

стабиль куркынычсызлык дәрәҗәсе.

**База сценарий (2 вариант)**. Ресурслар чикләүләрен үтүгә юнәлдерелгән кирәкле чараларның гамәлгә ашырылуын күздә тота. Башлыча фаразланган вакытларда түбән гамәлгә ашыру куркынычы булган проектлар һәм югары дәрәҗәдәге куркынычлар белән бәйле кайбер төп эре проектлар тормышка ашырыла.

Сценарийның төп параметрлары:

республика үсешенең потенциалын гамәлгә ашыруның югары дәрәҗәсе;

традицион өлкәләрдәге конкурентлык өстенлекләрен ныгыту һәм киңәйтү (шул исәптән барлык икътисад тармакларында һәм социаль өлкәдә технология дәрәҗәсен күтәрү һәм хезмәт җитештерүчәнлеге үсү нигезендә), индустриаль һәм постиндустриаль үсеш факторлары балансын саклаучы кластерлар активлашуы нигезендә тотрыклы баланслаштырылган үсеш моделе формалаштыру максаты белән яңа тармакларда конкурентлыкка сәләтне үстерүне стимуллаштыру;

социаль өлкәне тирән модернизацияләү аша иркен тормыш, социаль иминлек, килешү һәм куркынычсызлык нигезендә кеше потенциалын үстерү;

икътисадның чагыштырма өстнелекләрен кулллануны күздә тоткан күпчелек озак вакытлы өстенлекле проектлар һәм программаларны гамәлгә ашыру;

инвестицион климатны шактый дәрәҗәдә яхшырту, шул исәптән чит ил инвесторлары өчен;

баланслаштырылган пространство үсеше (яңа икътисадый үстерү үзәкләре булдыру, пространство сыйфаты үсеше) һәм төбәкара һәм халыкара социально-икътисадый пространствода шактый дәрәҗәдә интеграцияләү;

тотрыклы үсешкә китерүче институциональ мохит булдыру.

**Оптимистик сценарий (3 вариант)**. Республиканың үсеш потенциалын тулысынча ачуны, глобаль конкурентлык сәләтенә ирешүне күздә тота. Кластерлар активлашуы уңышлы гамәлгә ашырыла: (башлыча бишенче технологик тәртип эле-

ментлары белән дүртенче технологик тәртиптәге) «хәзерге икътисад» тулысынча модернизацияләнә, (җиденче технологик тәртип барлыкка килү мөмкинлеге белән бишенче – алтынчы технологик тәртипләрдәге) «акыллы икътисад» секторы булдырыла.

***2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең төп күрсәткечләре фаразы***

**Демографик күрсәткечләр**

Туучылар санын, кеше гомеренең озынлыгын арттыруга, үлүчеләр санын киметүгә юнәлтелгән Татарстан Республикасының демография сәясәтен гамәлгә ашыру, шулай ук республикада яшәү өчен уңайлы шартлар тудыру буенча чараларны тормышка ашыру табигый һәм миграцион артымның тотрыклы траекториясен тәэмин итә, һәм бу, гомумән алганда, даими халыкның уртача еллык санының 2014 елда 3 846,7 мең кешегә кадәр артуына китерә (белешмә буларак: 2013 елда 3 830,2 мең кеше).

Озак вакытлы перспективада фаразның һәр өч варианты буенча, туучылар санының үлүчеләр саныннан артыграк булган соңгы елларның уңай тенденциясе сакланачак. Шул ук вакытта **фаразның инерцион сценарие буенча** даими халык саны 100,2 процент дәрәҗәсендәге уртача еллык үсеш темпы белән үсеш тенденциясенә булачак һәм 2015 елда 3 855,8 мең кешедән 2030 елда 3 958,2 мең кешегә кадәр артачак (2015 елга карата 2,7 процентка үсү).

**Фаразның база сценарие буенча** даими халык саны югарырак темплар белән артачак (уртача елына 100,5 процент тирәсе) һәм 2030 елга 4 181,5 мең кешегә кадәр артачак (2015 ел дәрәҗәсенә карата 8,4 процентка).

**Оптимистик сценарий буенча** халык санының уртача еллык үсеш темпы 100,9 процент тәшкил итәчәк. Даими халык саны 2030 елга 4 385 кешегә кадәр артачак (2015 ел дәрәҗәсенә карата 13,7 процентка).

**Икътисадый күрсәткечләр**

Тулаем төбәк продуктының динамикасын озак вакытлы перспективада билгеләүче икътисадның төп секторларның үстерү фаразлары түбәндәге бәяләмәләрдән чыга.

Эшчәнлекнең җитештерү төрләрен үстерүнең фаразлау параметрларын исәпләгәндә, бер яктан, товарлар һәм хезмәтләр глобаль базарында үсә баручы конкурентлык, сату базарында һәм продукцияләр белән тәэмин итүдә киеренкелек, икенче яктан – техник модернизацияләү һәм төп фондларны яңарту, яңа югары нәтиҗәле производстволар булдыру һәм югары технологияле продукция чыгаруны үзләштерү, шулай ук импортны алыштыру процессларын киңәйтү исәбенә производстволарның конкурентлыкка сәләтен һәм нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлгәнлек игътибарга алына.

**Инерцион сценарий (1 вариант)** икътисад үсешенең уртача озак вакытлы темплары белән характерлана. Тулаем төбәк продуктының уртача еллык үсеш темплары 2016 – 2018 елларда 101,5 процент дәрәҗәсендә, 2019 – 2021 елларда – 102,1 процент, 2022 – 2024 елларда – 101,6 процент, 2025 – 2030 елларда 101,6 про-

цент дәрәҗәсендә фаразлана. Тулаем төбәк продуктының күләме 2030 елга 2015 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 1,3 тапкырга артачак.

Сәнәгать җитештерүенең уртача еллык үсеш темплары 2016 – 2018 елларда – 102,3 процент, 2019 – 2021 елларда – 103,7 процент, 2022 – 2030 елларда 101,5 процент дәрәҗәсендә фаразлана. 2030 елга сәнәгать җитештерүе күләме 2015 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 1,4 тапкырга артачак.

Сәнәгать җитештерүе үсешенә төп өлешне нефть-газ химиясе һәм машина төзү комплекслары кертәчәк. Фаразлана торган чорда кайбер эре республика инвестиция проектларын планлаштырылган куәтенә чыгару көтелә, шул ук вакытта аларны гамәлгә ашыру вакытларын күчерү ихтималы күздә тотыла.

Татарстан Республикасында 2020 елга кадәрге чорда ел саен 17 млн.тонна тирәсе углеводород чималын эшкәртү планлаштырыла. 2020 елдан, «ТАНЕКО» ачык акционерлык җәмгыятенә ЭЛОУ-АВТ-6 яңа җайланмасын керткәннән соң, нефть эшкәртү күләмнәре 21 млн.тоннадан артачак.

Нефть продуктлары җитештерүдә үсеш өстәлгән югары бәяле тонык, аеручa кыйммәтле һәм югары ликвидлы нефть продуктларын җитештерү күләмнәрен арттыру исәбенә күздә тотыла.

2016 елда «ТАНЕКО» ачык акционерлык җәмгыятендә автомобиль бензиннарын җитештерүне башлап җибәрү көтелә, 2017 елда «ТАИФ-НК» ачык акционерлык җәмгыятендә авыр калдыкларны тирән эшкәртү буенча комплексны башлап җибәрү белән дизель ягулыгының, автомобиль бензинының һәм турыдан-туры кудырылган бензинның өстәмә күләмнәре җитештереләчәк.

Нефтехимияне үстерүнең төп бурычлары арасында – республикада чыгарыла торган полимер һәм башка нефть химиясе продукциясен эшкәртүне алга таба тирәнәйтү, шул исәптән кече тармак бизнесын үстерү исәбенә.

Химия производстволарының үсеш темпы «Түбән Кама нефть химиясе» гамави акционерлык җәмгыяте, «Казан органик синтез» ачык акционерлык җәмгыяте, «Нәфис Косметикс» ачык акционерлык җәмгыяте, «Менделеевсказот» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Түбән Кама техуглерод» ачык акционерлык җәмгыяте, «Тат-химфармпрепараты» ачык акционерлык җәмгыяте, «Л.Я.Карпов исемендәге химия заводы» ачык акционерлык җәмгыяте, «Казан синтетик каучук заводы» ачык акционерлык җәмгыяте, шулай ук кайбер кече предприятиеләрнең проектларын гамәлгә ашыру белән бәйле.

Агымдагы һәм киләсе елларда әлеге төр икътисадый эшчәнлек буенча җитештерү күрсәткечләренең үсеше, башлыча, яңа химия производстволары төзү һәм гамәлдәгеләрен төзекләндерү буенча эре инвестиция проектларын гамәлгә ашыру исәбенә фаразлана.

2015 году елда «Түбән Кама нефть химиясе» гамави акционерлык җәмгыятендә шулай ук синтетик каучуклар җитештерү буенча куәтләрне арттыру эшләре дәвам итәчәк. Синтетик каучукларны җитештерүнең 2016 елга гомуми куәте елына 660 мең тонна тәшкил итәчәк.

2015 елның икенче ярты еллыгында Менделеевск шәһәрендә («Аммоний» ачык акционерлык җәмгыяте) 400 мең тоннадан күбрәк күләмдә продукция чыгарып, аммиак, метанол һәм гранулалы карбамид җитештерү буенча беренче чиратта интегрирацияләнгән комплексны кулланылышка кертү планлаштырыла.

2016 ел ахырында елына 40 мең тонна продукция куәтле метилхлорсиланнар җитештерү буенча «КЗСК-Силикон» ачык акционерлык җәмгыяте заводын кулланылышка кертү көтелә.

2017 елда җаваплылыгы чикләнгән «Түбән Кама тоташ металл кордлы шиннар заводы» җәмгыяте проектлар куәтенә чыгуы планлаштырыла.

2018 елда планируется Түбән Кама шәһәрендә («Түбән Кама нефть химиясе» гамави акционерлык җәмгыяте) ЭП-1000 олефин комплексын кулланылышка кертеп җибәрү планлаштырыла.

Предполагается, Фаразланган чорда кече инновация компанияләре, шул исәптән «Алабуга» МИЗ, «Химград» технополисы, «Кама Аланы» индустрия паркы резидентлары тарафыннан җитештерелә торган билгеләнгән үзенчәлеклеәре белән композиция материаллары рәте киңәячәк.

Транспорт машиналары төзү предприятиеләре эшенең нәтиҗәләре, беренче чиратта, «КАМАЗ» ачык акционерлык җәмгыяте күрсәткечләре белән билгеләнә – республикада машина төзү комплексының төп предприятиесе. Предприятие 2020 елга автомобиль чыгару күләмнәрен 63 мең данәгә кадәр арттырырга планлаштыра. «КАМАЗ» ачык акционерлык җәмгыятенең төп үсеш юнәлешләре: «Даймлер» компаниясе белән интеграцияне алга таба үстерү; продуктлар портфелен киңәйтү; «Евро-4» һәм «Евро-5» экологик класс автомобильләрен эшләү һәм җитештерүгә кую, газ ягулыгындагы һәм катнаш приводлы автомобильләр төркемен үстерү; экспорт тәэминатын арттыру һәм чит илдә җыю производстволарын булдыру.

Татарстанда («Алабуга» махсус икътисадый зонасында һәм Чаллы шәһәрендә) ике заводы булган Ford Sollers уртак предприятиесе республика автомобиль төзелешен үстерүдә мөһим урын алып тора.

Компаниянең мөһим үсеш этабы булып «Алабуга» махсус икътисадый зонасында Ford Sollers двигательләр заводын төзү тора. Двигательләр җитештерүне башлап җибәрү 2015 ел ахырына планлаштырылган. Заводның еллык куәте беренче этапта алга таба елына 200 мең двигательгә кадәр арттыру ихтималы белән 105 мең двигатель тәшкил итә. Бу Ford Sollers компаниясенә Россия Федерациясендә җитештерелүче Ford автомобильләренең 30 процентган да ким булмаган двигательләре белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

«Казан вертолет заводы» ачык акционерлык җәмгыяте үзенең җитештерү күләмнәрен арттырырга планлаштыра. Ми-8/17 вертолетлар төркемен сериялэп чыгару белән беррәттән, сериялэп җитештерүгә «Ансат» вертолетлары кертеп җибәрелде. Ми-38 вертолетын сериялэп җитештерүне башлау планлаштырыла.

Республиканың төзелеш материаллары сәнәгате предприятиеләре, гомумән алганда, төзелеш тармагын тәэмин итәләр һәм базар соравын төп төзелеш материалларында канәгатьләндерәләр. Татарстан Республикасы төзелеш материаллары сәнәгатен үстерүнең өстенлекле юнәлешләреннән берсе – җитештерелә торган материалларның инновацияләр белән тулылык өлешен арттыру, заманча ресурслар һәм энергия саклаучы материаллар җитештерү һәм куллану. Бүгенге көндә республикадаюка катламлы җылылык үткәрми торган япмалар, светодиодлар нигезендә яктырту системалары һәм башкалар кебек уникаль кулланылыш сыйфатларына ия булган материаллар җитештерелә һәм уңышлы кулланыла.

«Алабуга» МИЗ территориясендә «Алабуга-Волокно» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (елына 1 500 тонна куәтле) углерод җепселләрен һәм җаваплылыгы чикләнгән «Армстронг Билдинг Продактс» җәмгыяте (елына 22 млн.кв.метр продукция куәтле) асылмалы түшәм системаларын җитештерүне башлап җибәрү күзәтелә. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында 8 мең тонна куәтле цемент терминалын һәм «Алабуга» махсус икътисадый зонасында композит пыяла-пластик полиэфир торбаларны, пыяла-пластик эпоксид торбаларны, фланецларны, муфталарны һәм елына 560 километрдан артыграк куәтле башка торба продукциясен сериялэп сәнәгать җитештерүе заводын төзү буенча проектлар тормышка ашыру стадиясендә тора.

Фаразлана торган чорда «Алабуга» махсус икътисадый зонасын актив үстерү инфраструктураны үстерү өлешендә дә, потенциаль резидентлар җәлеп итү өлешендә дә дәвам итәчәк. «Алабуга» МИЗ үстерү стратегиясе нигезендә 2023 елга җәлеп ителгән резидентлар санын 360 млрд сум тирәсе инвестицияләр күләме белән 120 компаниягә кадәр үстерү, 16 мең яна эш урыны булдыру планлаштырыла.

Шулай ук техник-кертү тибындагы «Иннополис» яңа булдырылган махсус икътисадый зонасына – югары һәм мәгълүмати технологияләр өлкәсендә махсуслашкан инновацияләр киләчәк шәһәрен булдыруга юнәлтелгән федераль әһәмияттәге проектка – актив рәвештә резидентлар туплау фаразлана.

Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүнең уртача еллык үсеш темплары 2016 – 2018 елларда – 102,3 процент, 2019 – 2030 елларда 101,9 процент дәрәҗәсендә фаразлана. Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләме 2030 елга 2015 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 1,3 тапкырга артачак. Агросәнәгать комплексын үстерүнең иң мөһим юнәлеше булып аны модернизацияләү тора, шул исәптән эшкәртүне, үлчәп тору технологияләрен, төргәкләү һәм саклауны үстерү. Бу – сәүдә челтәрләрендәге республика товарларын киңәйтүгә һәм импортны алыштыруга кирәк булган мөһим шартларның берсе.

Ваклап сату әйләнеше, фараз буенча, уртача 2016 – 2018 елларда 100,3 процент дәрәҗәсендә, 2019 – 2021 елларда – 102,8 процент, 2022 – 2024 елларда – 102,9 процент, 2025 – 2030 елларда 102,4 процент дәрәҗәсендә үсәчәк. 2030 елга ваклап сату әйләнеше 2015 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 1,4 тапкырга артачак.

Республиканың төзелеш комплексында уртача еллык темплар, фараз буенча, 2016 – 2018 елларда – 99,2 процент, 2019 – 2021 елларда – 100,4 процент, 2022 – 2024 елларда – 100,8 процент, 2025 – 2030 еллард 102,5 процент тәшкил итәчәк. 2030 елга күрсәтелгән эшчәнлек төре буенча эшләр күләме 2015 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 1,2 тапкырга артачак.

Төп капиталга инвестицияләрнең уртача еллык үсеш темплары 2016 – 2018 елларда – 101,9 процент, 2019 – 2021 елларда – 103,3 процент, 2022 – 2024 елларда – 102,4 процент, 2025 – 2030 елларда 101,9 процент дәрәҗәсендә үсәчәк. 2030 елга инвестицияләр күләме 2015 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 1,4 тапкырга артачак.

**База сценарий (2 вариант)** ресурслар чикләүләрен үтүгә юнәлтелгән кирәкле чаралар гамәлгә ашырылачакны, шулай ук геосәяси киеренкелек үсеше белән бәйле тискәре йогынтыларны киметүгә юнәлтелгән активрак дәүләт сәясәте

үткәреләчәкне, һәм җитештерелә торган продукциянең тотрыклы озак вакытлы үсеше һәм конкурентлыкка сәләтен күтәрү өчен шартлар тудыруны күздә тота.

Күрсәтелгән вариант икътисадый үсешнең инвестицияләргә юнәлеше көчәюю һәм инерцион сценарий белән чагыштырганда төп икътисад секторларының югарырак үсеш темплары белән характерлана. Күрсәтелгән проектларның күпчелеге план вакытларында гамәлгә ашырыла.

Тулаем төбәк продуктының уртача еллык үсеш темплары 2016 – 2018 елларда 103 процент дәрәҗәсендә, в 2019 – 2021 елларда – 104,6 процент, 2022 – 2024 елларда – 104,8 процент, 2025 – 2030 елларда 103,8 процент дәрәҗәсендә фаразлана. Тулаем төбәк продуктының күләме 2030 елга 2015 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 1,8 тапкырга артачак.

Сәнәгать җитештерүенең уртача еллык үсеш темплары 2016 – 2018 елларда, фараз буенча, 102,9 процент, 2019 – 2021 елларда – 105,1 процент, 2022 – 2024 елларда – 104,8 процент, 2025 – 2030 елларда – 103,8 процент тәшкил итәчәк. 2030 елга сәнәгать җитештерүе күләме 2015 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 1,8 тапкырга артачак.

Авыл хуҗалыгында уңайлы һава шартлары булганда һәм инвестицияләр белән тулыландырылганда уртача еллык үсеш темплары 2016 – 2018 елларда 103,3 процент дәрәҗәсендә, 2019 – 2021 елларда – 103,7 процент, 2022 – 2024 елларда – 104,9 процент, 2025 – 2030 елларда – 103,7 процент дәрәҗәсендә фаразлана. Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләме 2030 елга 2015 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 1,8 тапкырга артачак.

Ваклап сату әйләнеше уртача 2016 – 2018 елларда – 102,9 процент, 2019 – 2021 елларда – 104,5 процент, 2022 – 2024 елларда – 105,7 процент, 2025 – 2030 елларда – 104,4 процент дәрәҗәсендә үсәчәк. Ваклап сатудагы уңай үзгәрешләрнең озак вакытлы перспективада төп этәргечләре түбәндәгеләр булачак: халыкның акчалата керемнәре үсүе, инфляция басымы кимүе, үзебезнең ил предприятиеләре тарафыннан кулланучылар сыйфатлары буенча халык таләпләренә җавап бирүче конкурентлыкка сәләтле продукция чыгаруны арттыру. Нәтиҗәдә 2030 елга ваклап сату әйләнеше 2015 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 1,9 тапкырга артачак.

«Төзелеш» эшчәнлек төре буенча эшләр күләме уртача 2016 – 2018 елларда – 101,1 процент, 2019 – 2021 елларда – 102,1 процент, 2022 – 2024 елларда – 103,1 процент, 2025 – 2030 елларда – 104,6 процент дәрәҗәсендә үсәчәк. 2030 елга күрсәтелгән эшчәнлек төре буенча эшләр күләме 2015 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 1,6 тапкырга артачак.

Төп капиталга инвестицияләрнең уртача еллык үсеш темплары 2016 – 2018 елларда – 103,7 процент, 2019 – 2021 елларда – 105,3 процент, 2022 – 2024 елларда – 103,7 процент, 2025 – 2030 елларда – 102,6 процент дәрәҗәсендә фаразлана. 2030 елга төп капиталга инвестицияләр күләме 2015 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 1,7 тапкырга артачак.

Татарстан Республикасын үстерү фаразының база сценариендә дәүләт программаларының төп параметрлары исәпкә алына, шул исәптән инфраструктура үсеше, социаль һәм кадрлар белән тәэмин итү өлкәләрендә.

**Оптимистик сценарий (3 вариант)** уңай тышкы икътисадый хәлне, нефтькә чагыштырмача югары бәя белән бергә халыкара капитал базарларындагы чикләүләрне бетерүне, республика потенциалын тулысынча ачу өчен мөмкинлекләр булуны күздә тота. Инвестиция проектларын, инерцион һәм база сценарийлары белән чагыштырганда, иртәрәк вакытларда гамәлгә ашыру ихтимал.

2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе нигезендә республиканың этаплар буенча яңа баланслаштырылган үсеш моделенә күчүе нәтиҗәсендә, кеше потенциалы һәм социаль пространство сыйфатының шактый дәрәҗәдә яхшыруы, хәзерге икътисадны структуралы модернизацияләү тирәнәюе, яна «акыллы икътисад» үсеше, инновацияләрнең икътисадый үсештә әйдәүче факторларга әйләнүе күзәтеләчәк.

Өч агломерациянең (Казан, Кама һәм Әлмәт) потенциалларын бер ук вакытта һәм яраштырып куллану, бердәм Идел-Кама метрополисын формалаштыру синергетик эффект нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы үсешенең сыйфатлы алга китешенә, аның конкурентлыкка сәләтен күтәрүгә китерәчәкләр, агломерация нәтиҗәләрен арттырачаклар.

Нәтиҗәдә тулаем төбәк продуктының күләме 2030 елда 2015 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 2,4 тапкырга артачак. Тулаем төбәк продуктының уртача еллык үсеш темплары 2016 – 2018 елларда – 104,9 процент, 2019 – 2021 елларда – 106,5 процент, 2022 – 2024 елларда – 107 процент, 2025 – 2030 елларда – 105,6 процент дәрәҗәсендә фаразлана.

2030 елга сәнәгать җитештерүе күләме 2015 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 2,5 тапкырга артачак. Сәнәгать җитештерүенең уртача еллык үсеш темплары 2016 – 2018 елларда – 105 процент, 2019 – 2021 елларда – 107,9 процент, 2022 – 2024 елларда – 107,3 процент, 2025 – 2030 елларда – 105,6 процент дәрәҗәсендә фаразлана.

Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүнең уртача еллык үсеш темплары 2016 – 2018 елларда – 104,5 процент, 2019 – 2021 елларда – 104,7 процент, 2022 – 2024 елларда – 105,9 процент, 2025 – 2030 елларда 104,4 процент дәрәҗәсендә фаразлана. Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләме 2030 елга 2015 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 2 тапкырга артачак.

Ваклап сату әйләнеше уртача 2016 – 2018 елларда – 104,7 процент, 2019 – 2021 елларда – 106,6 процент, 2022 – 2024 елларда – 107,4 процент, 2025 – 2030 елларда – 106,2 процент дәрәҗәсендә үсәчәк. 2030 елга ваклап сату әйләнеше 2015 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 2,5 тапкырга артачак.

«Төзелеш» эшчәнлек төре буенча эшләрнең күләме уртача 2016 – 2018 елларда – 104,6 процент, 2019 – 2021 елларда – 105,7 процент, 2022 – 2024 елларда – 106,1 процент, 2025 – 2030 елларда 106,5 процент дәрәҗәсендә үсәчәк. Нәтиҗәдә 2030 елга әлеге эшчәнлек төре буенча эшләрнең күләме 2015 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 2,4 тапкырга артачак.

Төп капиталга инвестицияләрнең уртача еллык үсеш темплары 2016 – 2018 елларда – 105 процент, 2019 – 2021 елларда – 106,1 процент, 2022 – 2024 елларда – 106,7 процент, 2025 – 2030 елларда 106,5 процент дәрәҗәсендә фаразлана. 2030 елга инвестицияләр күләме 2015 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 2,5 тапкырга артачак.

**Хезмәт һәм мәшгульлек күрсәткечләре**

Озак вакытлы перспективада гомуми икътисадый хәлне этаплар буенча яхшырту шартларында республикада социаль күрсәткечләрнең яхшыруы күзәтеләчәк – икътисадта мәшгуль булганнарның саны арту һәм эшсезлек дәрәҗәсе киму.

**Инерцион сценарий буенча** фараз нигезендә, республикада икътисадта мәшгуль булганнарның саны 2015 елда 1 816,8 мең кешедән 2030 елда 1 819 мең кешегә кадәр артачак (100,1 процент). Шул ук вакытта эшсезлек дәрәҗәсе (Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе буенча) 2015 елда 4,5 проценттан 2030 елда 3,8 процентка кадәр булачак.

Республикага югары квалификацияле белгечләрне җәлеп итү һәм әле хезмәт базарында булмаган халык катламнарын хезмәт эшчәнлегенә җәлеп итүне стимуллаштыру буенча актив дәүләт сәясәтен күздә тоткан **база сценарий буенча**, яңа производстволар кертү, кече эшмәкәрлекне үстерүне исәпкә алып, икътисадта мәшгуль булганнарның санын 2030 елда 1 986,1 мең кешегә кадәр арттыру фаразлана (2015 ел дәрәҗәсенә карата 109,3 процент). Шул ук вакытта 2030 елга эшсезлек дәрәҗәсе 3,7 процент дәрәҗәсе тирәсендә фаразлана.

**Оптимистик сценарийны** гамәлгә ашыру икътисадта мәшгуль булганнарның санын 2030 елда 2 143,9 мең кешегә кадәр арттырырга мөмкинлек бирәчәк (2015 ел дәрәҗәсенә карата 118 процент). Эшсезлек дәрәҗәсе (Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе буенча) 2030 елга 3,5 процентка кадәр төшәчәк.

---

| **Күрсәткечләр исеме** | **Үлчәү берәмлеге** | **Хисап** | | | | **Фараз** | | | | | | | | | | | | | | | | 2016 – 2018 еллар | 2019 – 2021 еллар | 2022 – 2024 еллар | 2025 – 2030 еллар | 2030 - 2015 еллар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | **2011 ел** | **2012 ел** | **2013 ел** | **2014 ел** | **2015 ел** | **2016 ел** | **2017 ел** | **2018 ел** | **2019 ел** | **2020 ел** | **2021 ел** | **2022 ел** | **2023 ел** | **2024 ел** | **2025 ел** | **2026 ел** | **2027 ел** | **2028 ел** | **2029 ел** | **2030 ел** | | | | | |
| Эшсезлек дәрәҗәсе (ХХО методологиясе буенча) | мәшгуль булганнарга карата % | 4,7 | 4,1 | 4,0 | 3,9 | 4,5 | 4,5 | 4,2 | 3,9 | 3,9 | 3,9 | 3,9 | 3,8 | 3,8 | 3,8 | 3,7 | 3,7 | 3,7 | 3,7 | 3,7 | 3,7 | | | | | |

